СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с.Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Решение
13 август 2018 ел | № 1-33

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.6 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

бункер - зур габаритлы калдыкларны җыю өчен билгеләнгән зур чүп-чар савыты;

1.2.6 пунктның 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

контейнер - эре габаритлы калдыклардан тыш каты коммуналь калдыкларны туплау өчен билгеләнгән чүп-чар җыю савыты;

1.3. 6 пунктның 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

контейнер мәйданчыгы - каты коммуналь калдыклар җыелу урыны, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм

халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзекләндерелгән һәм контейнерлар һәм бункерлар урнаштыру өчен билгеләнгән урын;
1.4. 9 пунктның 28 пунктчасын төшереп калдырырга;

2.Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 1 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен 2 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча түбәндәге составта кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем (алаг таба- эшче төркем) төзергә:

Рахимзянов Айрат Галимзянович - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башлыгы, эшче төркем рәисе;

Казаханова Лвриса Мансуровна - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, эшче төркем әгъзасы;

Кекишева Елена Михайловна - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге хисапчысы, эшче төркем әгъзасы.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча Ачык тыңлауларны 2018 елның 3 сентябрендә 9.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Мамадыш муниципаль районы, Соколка авылы, Мәктәб урамы, 38 йорт.

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы

Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын әлеге проектка кергән ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә, һәм проектны икенче укылышта кабул итү өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советына карауга кертүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башлыгы А.Г. Рахимзяновка йөкләргә.

Башлык,
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге Советы рәисе А.Г. Рахимзянов/

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге
Советының 13.08.2018 ел,
№ 1-33 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибе

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәр Соколка авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422181, Татарстан Республиксы, Мамадыш районы, Соколка авылы, Мәктәб ур., 38 й. адресы буенча (885563) 3-82-05 тел./факс, e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru буенча язмача формада Ф.И.А.и туу датасын күрсәтеп түбәндәге таблицада тутырылып җибәрелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проектының тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр әлеге карар игълан ителгән көннән алып эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

1. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422181, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Соколка авылы, Мәктәб ур., 38 й, телефон / факс (885563) 3-82-05 e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru. Гаризалар ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2.Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Соколка авыл җирлеге Советына һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге
Советының 13.08.2018 ел,
№ 1-33 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе

(муниципаль берәмлек уставы һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә»)

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге № 1-30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча Ачык тыңлаулар (алга таба-ачык тыңлаулар) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә үткәрелә.
2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен ачык тыңлауларда катнашучылар булып ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән затлар тора.
3. Халык тыңлауларында халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.
4. Халык тыңлауларында халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.
5. Тыңлауларда җирлек башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Җирлек башлыгы урынбасары, җирлек башлыгы вәкаләтләре бирелгән башка затлар катнаша ала.
6. Халык алдында тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне

исәпкә алу өчен рәис тәкъдиме буенча ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

**8.** Чыгышларның эзлеклелеге һәм вакыты, карала торган мәсьәләнең эчтәлегеН, ачык тыңлауларда катнашу өчен кергән язма гаризаларның санын һәм башка мәсьәләләрне исәпкә алып, ачык тыңлаулар уздыру регламенты белән билгеләнә.
Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин.

**9.** Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

**10.** Ачык тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

**11.** Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәп куела.

**12.** Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче имзалый һәм ул җирлек Советы материаллары белән бергә  саклана.